ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2024 г. Заинск № 243

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 16 февралендәге 106 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү турында» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2023 елның 30 августындагы 642 номерлы боерыгына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 16 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү турында” муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Административ регламентны түбәндәге эчтәлектәге 1.5.8. пункт белән тулыландырырга:
«1.5.8. «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән балаларга һәм «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре турында» 2016 елның 3 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль Законның 28.1 статьясында күрсәтелгән балаларга муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында чираттан тыш урыннар бирелә.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42